СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**Яңасала авыл җирлеге Советы**
**КАРАР**

**« 21 » май 2024 ел** **№ 94**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитетына Яңасала авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында тәкъдимен кабул итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт төзү һәм аның эшчәнлек тәртибен раслау;

җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү.

2. Арча район Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Яңасала авыл җирлеге башкарма комитетына:

Арча муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә Яңасала авыл җирлеге Советының 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына Яңасала авыл җирлеге бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү турында карары проектын эшләргә һәм карауга тапшырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл җирлеге башлыгы Сафин А.И.

СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003024